ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

28 декабрь, 2023 ел № 29/5

Шәһәр Советының җирле салымнар турында аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясенең Салым кодексы, шәһәр Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының «Җир салымы турында» 2016 елның 9 ноябрендәге 11/6 номерлы Карарына (Шәһәр Советының 2016 елның 15 декабрендәге 13/7, 2017 елның 15 декабрендәге 21/7, 2018 елның 21 февралендәге 23/9, 2018 елның 8 ноябрендәге 27/6, 2019 елның 7 октябрендәге 33/6, 2020 елның 21 февралендәге 37/6, 2022 елның 22 августындагы 16/8, 2022 елның 2 ноябрендәге 17/7, 2023 елның 25 октябрендәге 27/7 номерлы Карарлары редакциясендә), 4 пунктта түбәндәге эчтәлектәге 16 пунктча өстәп, үзгәреш кертергә:

«16) Яр Чаллы шәһәренең шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында «Ц-6 зонасы» дип билгеләнгән күпләп сату, туплау һәм вак житештерү зонасы территориясендә янгын нәтиҗәсендә зыян күргән күчемсез милек объектлары арендаторлары - оешмалар һәм физик затлар, салым салу объектлары дип танылган җир участокларына ия булган күчемсез мөлкәт объектлары арендаторлары - салым түләүче физик затларга 2022 һәм 2023 еллар өчен һәм салым түләүче оешмаларга 2023 һәм 2024 еллар өчен.».

2. Шәһәр Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның 22 октябрендәге 2/11 номерлы Карарына (Шәһәр Советының 2017 елның 15 декабрендәге 21/8, 2018 елның 8 ноябрендәге 27/7, 2019 елның 7 октябрендәге 33/7, 2019 елның 6 декабрендәге 34/8, 2020 елның 21 февралендәге 37/7, 2021 елның 27 маендагы 7/5, 2022 елның 2 ноябрендәге 17/7 номерлы Карарлары редакциясендә), түбәндәге эчтәлектәге 4.2 пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«4.2. Яр Чаллы шәһәренең шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында «Ц-6 зонасы» дип билгеләнгән күпләп сату, туплау һәм вак житештерү зонасы территориясендә янгын нәтиҗәсендә зыян күргән, салым салу объекты булган милек хокукына ия булган күчемсез милек объектлары арендаторлары - физик затларны 2022 һәм 2023 еллар өчен салым түләүдән азат итәргә.

Салым ташламасына хокукы булган салым түләүчеләр салым органына салым ташламасын бирү турында гариза, шулай ук салым түләүченең салым

ташламасына хокукын раслаучы документлар тапшыралар.».

3. Әлеге Карар рәсми бастырылган көннән үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан соң барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләр өчен гамәлдә.

4. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев